# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 1 25.11.2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге составына керүче Мәндей авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез 2024 елда Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам яктырту челтәрләрен урнаштыру (светодиодлы лампаларны сатып алу, урнаштыру)
- гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту(грейдер белән юлларны тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 129 кеше, халык җыенында катнашучылар саны 88 кеше кергән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 88 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы составына керүче Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндәй авылында узган халык җыенын халык җыенын утте дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.
2. "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән:

- урам яктырту челтәрләрен урнаштыру (светодиодлы лампаларны сатып алу, урнаштыру)

- авыл мәдәният йорты территориясен төзекләндерү (авыл мәдәният йорты территориясен һәм Бөек Ватан сугышы һәйкәлен коймасын ясау һәм урнаштыру)
- гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту(грейдер белән юлларны тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү).

3.Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәндәй авылы, Ялантау ур., 36б йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдулавыл җирлеге башлыгы: Н.А. Фатхетдинов